СОВЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

**КАРАРЫ**

**31 октябрь 2022 ел** **№7**

**Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль Шушмабаш авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 19 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.

2.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 19 ноябренә 12 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 19 ноябренә 14 сәгать 00 минутта халык җыенының өченче этабын билгеләргә.

4.Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1в йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2022 елның 19 ноябренә 16 сәгать 00 минутта халык җыенының дүртенче этабын билгеләргә.

5. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Тукай урамында яшәүчеләр.

2нче этап: Такташ, Урак һәм Чүкеч, Тынычлык урамында яшәүчеләр.

3нче этап: Мәктәп, Яшьләр, Төньяк, Яр буе урамында яшәүчеләр.

4нче этап: Сәгъдуллин, Җиңү, Бакча урамында яшәүчеләр.

6. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

“Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Шушмабаш авылында Төньяк һәм Мәктәп урамнары арасына юлга нигез салу һәм вак таш җәю;
- Тукай, Бакча, Яр буе, Сәгъдуллин урамнарында юл-урам челтәренең юл полотносында чокырларны ремонтлау?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

7. Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге Шушмабаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы, Шушмабаш авылы, Мәктәп урамы, 1б йорт, Мәктәп урамы, 5 йорт, Мәктәп урамы 8 йорт адреслары буенча, Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

СОВЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН • АРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН • МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ ШУШМАБАШСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ • ОГРН 1121690000210 • ИНН 1609012678